ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

29 август 2023 ел № 740

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын раслау турында**

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2013 елның 30 ноябрендәге 939 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган җир кишәрлекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган биналарда яки башка күчемсез милектә, милек формасына карамастан, реклама конструкцияләрен урнаштыру схемаларын алдан килештерү тәртибенә һәм аңа кертелгән үзгәрешләргә ярашлы рәвештә, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы проектын килештерү турында» Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2023 елның 04 августындагы 6201 номерлы хаты нигезендә, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын расларга (1 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын раслау турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 21 августындагы 888 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р. М. Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
29.08.2023 ел, № 740
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы**

## 1. Схеманы куллану өлкәсе

Әлеге схема Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезләмәләренә туры китереп урнаштыру урыннарын билгели.

Схема рекламаны щитлар, стендлар, электрон таблолар һәм реклама конструкцияләреннән гыйбарәт башка техник чаралар ярдәмендә кулланганда файдаланыла.

Схема бина стеналарында һәм түбәләрендә урнашкан реклама конструкцияләренә, корылмаларның конструктив элементларына һәм төзелеш алып барылмаган территориядә аерым торучы корылмаларга карата кулланыла.

Схеманы кулланганда реклама конструкциясенең урнашкан урыны һәм төре җайга салу предметы булып тора.

Схема түбәндәгеләрдән тора:

реклама конструкцияләренең төрләрен билгеләүче аңлатма язуы һәм Схемага үзгәрешләр кертү таләп ителгән очраклар исемлеге;

карталар һәм башка график материаллар;

реклама конструкцияләре исемлеге.

Схемада гамәлдәге реклама конструкцияләре, аларны урнаштыру рөхсәт ителгән урыннар һәм рөхсәт ителмәгән зоналар күрсәтелде.

## 2.Терминнар

Тышкы реклама (реклама конструкцияләре) - щитлы конструкцияләр, стендлар, тумбалар, панель-кронштейннар, стена панносы, электрон табло, проекция, ориентирлаучы мәгълүмат элементлары булган конструкцияләр, хәрәкәт маршрутлары һәм аларда булган объектлар турында мәгълүмат бирүче, реклама мәгълүматлы рамнар һәм аларда урнаштыру өчен функциональ яктан билгеләнгән, шул исәптән тышкы стеналарда, түбәләрдә һәм биналарның, корылмаларның башка конструктив элементларындагы башка техник чаралар.

Реклама кыры - реклама тарату яки мәгълүмат урнаштыру өчен билгеләнгән реклама конструкциясе өслеге.

Реклама конструкциясе төре - реклама конструкциясен урнаштыру ысулына, реклама кыры мәйданына, конструктив карарларга һәм урнаштырыла

торган мәгълүматның максатларына бәйле рәвештә классификацияләү.

Тартылу объекты - халыкка хезмәт күрсәтү объекты яисә сәүдә объекты, социаль әһәмияткә ия объект, җәмәгать транспорты тукталу, иҗтимагый яисә массакүләм чаралар уздыру урыны, мәдәни мирас объекты.

### 3. Реклама конструкциясе төрләре

Әлеге схеманы куллану максатларында аларны урнаштыру ысулы буенча реклама конструкцияләренең түбәндәге төрләре билгеләнә:

1) аерым торучы зур габаритлы - реклама кырының иң озын ягы 6 һәм аннан да күбрәк метр озынлыгында яисә 18 һәм аннан да артыграк квадрат метрлы стелалар, щитлар һәм электрон таблолар. Реклама конструкцияләренең әлеге төренә шулай ук реклама тармагында кабул ителгән щитларның стандарт конструкцияләре атамалары - супербордлар, суперсайтлар, еврощитлар, аркалар керә. Юлның бер ягында аерым урнашкан тышкы реклама чаралары арасы 150 метрдан да ким булмаска тиеш.

2) реклама кырының иң озын ягы 6 метрдан да ким булган, мәйданы 3 кв. метрдан 18 кв. метрга кадәр булган уртача габаритлы стелалар, щитлар һәм электрон табло. Реклама конструкцияләренең әлеге төренә шулай ук реклама тармагында кабул ителгән щитларның стандарт конструкцияләре исемнәре - ситибордлар, билбордлар керә. Юлның бер ягында аерым урнашкан тышкы реклама чаралары арасы 100 метрдан да ким булмаска тиеш.

3) мәйданы 3 квадрат метрдан кимрәк булган стелалар һәм щитлар, тартылу объектлары, тумбалар, стендлар турында мәгълүмат бирү билгеләре, реклама модуле белән күрсәткечләр, штендерлар. Реклама конструкцияләренең әлеге төренә шулай ук реклама тармагында кабул ителгән стандарт конструкцияләр исемнәре - сити-форматлар, пилларслар, пилоннар керә. Юлның бер ягында аерым урнашкан тышкы реклама чаралары арасы 30 метрдан да ким булмаска тиеш.

4) Биналар һәм корылмалар стеналарында, коймаларда һәм төзелеш челтәрләрендә урнашкан стена паннолары. Стена панносы тәрәзәләрне, керү төркемнәрен һәм фасадларның декоратив детальләрен, шулай ук үтә күренмәле һәм аркылы өслеге һәм декоратив элементлары булган коймаларны капларга тиеш түгел. Стена панносының зурлыгы таяныч өслегенең мәйданы һәм тибы белән билгеләнә:

- тәрәзәләре булмаган фасадлар өчен фасад мәйданының 50 %тан артыграк түгел;
- тәрәзәле фасадлар өчен фасад мәйданының 30% тан артыграк түгел;
- төзелеш челтәрләре өчен панноның зурлыгы чикләнми;
- киртәләрдә 12 кв.метрдан артык түгел, реклама конструкциясенең киртәнең таяныч элементлары биеклегеннән 50% ка артмавы рөхсәт ителә.

### 4. Реклама конструкцияләрен урнаштыруга таләпләр

Реклама конструкцияләрен урнаштыру түбәндәге норматив документлар

белән регламентлана:

1) «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон;

2) «Автомобиль юлларында һәм шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрендә тышкы реклама. Тышкы реклама чараларына гомуми техник таләпләр. Урнаштыру кагыйдәләре. ГОСТ Р 52044-2003.»

Схемада реклама конструкцияләрен урнаштыруга ГОСТ Р 52044-2003 таләпләре һәм электр челтәрләренең саклау зоналарын, элемтә линияләрен һәм газ бүлү челтәрләрен куллануны чикли торган норматив документлар нигезендә чикләүләр белән зоналар сайлап алынды:

1) «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының саклау зоналарын билгеләү тәртибе һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартлары турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары;

2) «Россия Федерациясе элемтә линияләрен һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1995 елның 9 июнендәге 578 номерлы карары;

3) "Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында" РФ Хөкүмәтенең 2000 елның 20 ноябрендәге 878 номерлы карары.

Электр челтәрләренең, элемтә линияләренең, газ бүлү челтәрләренең сак зоналарында теләсә кайсы объектны, шул исәптән реклама конструкцияләрен төзү һәм урнаштыру тыела.

Реклама конструкцияләрен урнаштыру урыннары схемада шартлы билгеләр белән күрсәтелгән. Реклама конструкциясенең төгәл урыны инженер эзләнүләрен, җир асты һәм җир өсте челтәрләренең булуын, юл полотносына һәм капиталь төзелеш объектларына карата кирәкле чигенешләрне һәм интервалларны саклауны исәпкә алып билгеләнә.

Автомобиль юлының юл буе полосасында реклама конструкциясе урнаштырганда хезмәт күрсәтүче оешмадан килештерү алырга кирәк.

### 5. Схемага үзгәрешләр кертү

Реклама конструкцияләрен урнаштыру төрен һәм урынын билгеләүче карталарның, график материалларның эчтәлеген үзгәртү кирәк булганда, ул "Реклама турында" 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Шулай ук Схемага түбәндәге очракларда үзгәрешләр кертү таләп ителә:

урнаштыру мөмкин булган урынга яңа реклама конструкцияләре урнаштыру - реклама конструкцияләре исемлегенә үзгәрешләр кертү;

Схеманың гамәлдә булуы Арча муниципаль районы территориясенең бер өлешендә таралган саен, карталар схемасын тулыландыру - 6 бүлеккә үзгәрешләр кертү.

төзелеш башлану, реклама конструкциясен урнаштыру яки аны эксплуатацияләү мөмкинлегенә йогынты ясый торган капиталь төзелеш объектларын эксплуатациягә кертү - график материалларга үзгәрешләр кертү

(реклама конструкциясенең башка төренә шартлы билге үзгәрү яки аны юкка чыгару);

реклама конструкцияләре төрләренең санын төгәлләштерү һәм тасвирлау кирәклеге - 3 бүлеккә һәм график материалларга үзгәрешләр кертү (реклама конструкциясенең башка төренә шартлы билгене үзгәртү яисә аны юкка чыгару).

**6. Схема карталарының составы**

1) Схема составына керә торган карталар әзерләнгән территорияләрнең күзәтү схемасы.

2) 1 бит. Арча шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасы.

3) 2 бит. Арча шәһәре территориясендә стена панноларын урнаштыру схемасы.

**7. Реклама конструкцияләре исемлеге**

| Схемада номеры | Реклама конструкциясенең төре | Урнашкан урыны | Реклама кырының бер ягы күләме, кв.м | Тибы һәм техник характеристикалары |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Аерым торучы зур габаритлы | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, «Казан-Малмыж» автомобиль юлы 57+000 км, (уңда) | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 2 | Аерым торучы зур габаритлы | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, «Казан-Малмыж» автомобиль юлы 64+337, (уңда) | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 3 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, «Казан-Малмыж» автомобиль юлы 64+488, (уңда) | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 4 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, «Казан-Малмыж» автомобиль юлы 64+550, (сулда) | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 5 | Аерым торучы зур габаритлы | Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, «Казан-Малмыж» автомобиль юлы 65+035 км, (уңда) | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 6 | Аерым торучы кечкенә габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, «Казан-Малмыж» автомобиль юлы 65+731 км (сулда) | 8 | 4 м * 2 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 7 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, «Казан-Малмыж» автомобиль юлы 65+995 км, (сулда) | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, «Казан-Малмыж» автомобиль юлы 66+093 км (сулда) | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 9 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча ш., Банк ур., 43 й. | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 10 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, «Казан-Малмыж» автомобиль юлы 67+320 км, (сулда) | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 11 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, «Казан-Малмыж» автомобиль юлы 67+520 км, (сулда) | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 12 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча ш., Большая ур. (Г. Исхакый урамы киселешендә) | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 13 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча ш., Большая ур. (Левитан урамы киселешендә) | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 14 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча ш., Большая ур., 75г й. | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 15 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча ш., Большая ур., 40 й. | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 16 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча ш., Большая ур., 13 й. | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 17 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча ш., Комсомольская ур., 50 й. | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 18 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Казансу елгасы аша күпер һәм Мостовая урамы ягына таба юл чаты | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 19 | Аерым торучы кечкенә габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, «Арча-Теләче» автомобиль юлы 1+310 км, (сулда) | 2,25 | 1,5 м * 1,5 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |
| 20 | Аерым торучы зур габаритлы | ТР, Арча муниципаль районы, «Арча-Сеже» автомобиль юлы 1+872, (сулда) | 18 | 6 м * 3 м зурлыгындагы ике яклы щитлы конструкция |

**Стена паннолары исемлеге**

| Схемада номер | Реклама конструкциясе төре | Урнашкан урыны | Реклама кыры күләме, кв.м. | Тибы һәм техник характеристикалары |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, . 65 лет Победы ур., 15а й. | 9 | Стена панносы |
| 2 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Таң урамы, 24 й. | 3 | Стена панносы |
| 3 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Г.Тукай урамы, 14 й. | 12 | Стена панносы |
| 4 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Г. Исхакый урамы, 1а й. | 20 | Стена панносы |
| 5 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Интернациональная урамы, 41 й. | 4 | Стена панносы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 6 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, «Казан-Малмыж» автомобиль юлы һәм Борһанов урамы киселеше | 7 | Стена панносы |
| 7 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, 40 лет Победы урамы, 10 йорт чиге | 7,5 | Стена панносы |
| 8 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, 40 лет Победы урамы, 1 й. | 8 | Стена панносы |
| 9 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, 40 лет Победы урамы, хуҗалык корылмалары | 8 | Стена панносы |
| 10 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, 40 лет Победы урамы, торак йорт | 15 | Стена панносы |
| 11 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, 40 лет Победы урамы, торак йорт | 15 | Стена панносы |
| 12 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, 40 лет Победы урамы, торак йорт | 15 | Стена панносы |
| 13 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, 40 лет Победы урамы, торак йорт | 15 | Стена панносы |
| 14 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Интернациональная урамы, 39 й. | 16 | Стена панносы |
| 15 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Банковская урамы , 1 й. | 6 | Стена панносы |
| 16 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Банковская урамы , 1 й. | 6 | Стена панносы |
| 17 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Большая урамы, 7 й. | 4 | Стена панносы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 18 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре,Большая урамы, 5 й. | 12 | Стена панносы |
| 19 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Большая урамы, 3 й. | 3 x 24 | Стена панносы |
| 20 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Большая урамы, 1а й. | 30 | Стена панносы |
| 21 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27/1 й. | 16 | Стена панносы |
| 22 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 21 й. | 16 | Стена панносы |
| 23 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы,22 й. | 4 | Стена панносы |
| 24 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 22 й. | 4 | Стена панносы |
| 25 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 22 й. | 2,5 | Стена панносы |
| 26 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Интернациональная урамы, 4 й. | 12 | Стена панносы |
| 27 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Интернациональная урамы, 8 й. | 9 | Стена панносы |
| 28 | Стена панносы | ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Интернациональная урамы, 39 й. | 3 | Стена панносы |

Инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И.Ә. Кадыйров